ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Ключищи  авылында
халык җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

30 ноябрь 2019 ел, 3нче номерлы карар

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Ключищи авылында гражданнар җыенының 2019 елның 28 ноябрендә һәм 30 ноябрендә узган этаплары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Ключищи авылында су челтәрен ремонтлау.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 125 граждан, җыенда катнашучылар саны 68 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 68 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында халык җыенын узды дип,  халык җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.
2. "2020  елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең  Ключищи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалардан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - Ключищи авылында су челтәрен ремонтлау” мәсьәләсе  буенча карарын танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен адресларга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов